**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 24 апрель № 241

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 - 2020 елларга Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 18 декабрь, 1006 нчы карары белән расланган «2014 - 2020 елларга Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 - 2020 елларга Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 18 декабрь, 1006 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 7 октябрь, 731 нче, 2014 ел, 29 ноябрь, 930 нчы, 2014 ел, 12 декабрь, 982 нче, 2015 ел, 4 август, 566 нчы, 2015 ел, 5 сентябрь, 640 нчы, 2016 ел, 27 сентябрь, 689 нчы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) расланган «2014 - 2020 елларга Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру» дәүләт программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программа паспортында:

«Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Программаны Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслау күләмнәре 300,787 млн. сум тәшкил итә, шул исәптән:

2014 елда – 39,324 млн. сум;
2015 елда – 32,724 млн. сум;
2016 елда – 42,624 млн. сум;
2017 елда – 40,371 млн. сум;
2018 елда – 48,302 млн. сум;

2019 елда – 43,422 млн. сум;
2020 елда – 54,02 млн. сум.

Программаны Россия Федерациясе бюджеты акчасы исәбеннән финанслау күләме 2014 елда 21,6008 млн. сум тәшкил итә.

Программаны Россия Федерациясе бюджеты акчасы исәбеннән финанслау күләме 2015 елда 17,96775 млн. сум тәшкил итә.

Программаны Россия Федерациясе бюджеты акчасы исәбеннән финанслау күләме 2016 елда 18,2494 млн. сум тәшкил итә.

Программаны Россия Федерациясе бюджеты акчасы исәбеннән финанслау күләме 2017 елда 9,1068 млн. сум тәшкил итә.

Искәрмә: финанслау күләмнәре фаразлау характерында һәм, Татарстан Республикасы бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен тәгаенләнергә тиеш.»;

«IV. Программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү» бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Программа чараларын финанслау Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән гамәлгә ашырылачак.

Программада программа чараларын тормышка ашыру өчен бюджеттан тыш чараларны (эшмәкәрләр, иганәчеләр акчасы) һәм муниципаль берәмлекләр бюджетлары акчаларын җәлеп итү каралган.

Программаны Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслау күләмнәре 300,787 млн. сум тәшкил итә, шул исәптән:
2014 елда – 39,324 млн. сум;
2015 елда – 32,724 млн. сум;
2016 елда – 42,624 млн. сум;
2017 елда – 40,371 млн. сум;
2018 елда – 48,302 млн. сум;
2019 елда – 43,422 млн. сум;
2020 елда – 54,02 млн. сум.

Финанслау күләмнәре фаразлау характерында һәм, Татарстан Республикасы бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен тәгаенләнергә тиеш.

Программаны Россия Федерациясе бюджеты акчасы исәбеннән финанслау күләме 2014 елда 21,6008 млн. сум тәшкил итә.

Программаны Россия Федерациясе бюджеты акчасы исәбеннән финанслау күләме 2015 елда 17,96775 млн. сум тәшкил итә.

Программаны Россия Федерациясе бюджеты акчасы исәбеннән финанслау күләме 2016 елда 18,2494 млн. сум тәшкил итә.

Программаны Россия Федерациясе бюджеты акчасы исәбеннән финанслау күләме 2017 елда 9,1068 млн. сум тәшкил итә.

Программа чаралары буенча максатлар, бурычлар, максатчан индикаторлар һәм нәтиҗәлелек күрсәткечләре, финанслау Программага 4 нче кушымтада китерелгән.»;

Программага 2 нче һәм 4 нче кушымталарны яңа редакциядә бәян итәргә (теркәлгәннәр).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\241.docx